**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.06.2019 Казан ш. № 191

Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Административ регламентын раслау турында

**боерам:**

1. Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының теркәлә торган Административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт буенча министрлыгының түбәндәге:

2016 елның 28 июленнән 460 нчы номерлы «Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт буенча министрлыгының Административ регламентын раслау турында»;

2017 елның 4 июленнән 420 нче номерлы «Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү

буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт буенча министрлыгының 2016 елның 28 июленнән 460 номерлы боерыгы белән расланган Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»;

2018 елның 19 апреленнән 185 нче номерлы «Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт буенча министрлыгының 2016 елның 28 июленнән 460 номерлы боерыгы белән расланган Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» боерыкларын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының
24.06.2019 дан № 191
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Регламент Татарстан Республикасында (алга таба – оешма) квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: (алга таба – гариза бирүче):

«тренер-укытучы» (өлкәнен дә кертеп) һәм «инструктор-методист» (өлкәнен дә кертеп) вазыйфаларында эшли торган, шулай ук вазыйфаларны башкару теге яки бу оешмада берьюлы ике эштә эшләгәндә дә, шулай ук хезмәт килешүе буенча билгеләнгән оешмадагы эше белән беррәттән вазыйфаларны ике эштә эшләү юлы белән башкарган оешмаларның педагогик хезмәткәрләре (алга таба – педагогик хезмәткәрләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: 420107, Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 нче йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне, 9:00 дан 18:00 кадәр, төшке аш вакыты 12:30 дан 13:30 кадәр.

Җәмәгать транспортында «Габдулла Тукай мәйданы» («Божра», «Балалар дөньясы») тукталышына кадәр:

1, 29, 30, 31, 35а, 37, 47, 71, 74, 74а, 90, 91 нче номерлы автобуслар;

- 2, 5, 6, 7, 8, 12, 17 нче номерлы троллейбуслар белән;
- «Тукай мәйданы» метро станциясенә кадәр килергә.

Үткәрү кәгазе һәм (яки) шәхесне раслый торган документ буенча үтәргә мөмкин.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм аны үтәү барышы турында мәгълүмат бирү оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге тарафыннан (алга таба – Бүлек) (843) 222-81-18 телефоны буенча башкарыла.

1.3.3. Татарстан Республикасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына кергән Министрлыкның рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре): http://minsport.tatarstan.ru/, электрон почта адресы:

minsport@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәге юллар белән алырга мөмкин:

1) Гариза бирүчеләр белән эш өчен Министрлык биналарында урнашкан дәүләт хезмәте, шулай ук Бүлекнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмати стендлар аша. Мәгълүмати стендларда Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында(подпунктларында) күрсәтелгән дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minsport.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләре) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итү ысулы аша (телефон буенча яки шәхсән);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать аша (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлыкның биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010 ел, 2 август, № 31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

2012 елның 29 декабреннән 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 31.12.2012, № 53, 7598 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маеннан 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012 ел, 7 май, № 19, 2338 маддә) (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 8 августыннан «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларын раслау турында» 678 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнары җыентыгы, 19.08.2013, № 33, 4381 маддә);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 26 августыннан «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсен раслау турында», «Мәгариф

хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикасы» бүлеге 761н номерлы боерыгы белән» (Россия газетасы, 20.10.2010, № 237, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 761н номерлы боерыгы);

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 7 апреленнән «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибен раслау турында» 276 номерлы боерыгы (Россия газетасы, 04.06.2014, № 124) (алга таба – Аттестация тәртибе);

2013 елның 22 июленнән «Мәгариф турында» 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, № 7, июль, 2013, 977 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – 68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

2005 елның 6 июлендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 315 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы турында «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы мәсьәләләре» нигезләмә (алга таба – 315 нче нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыелмасы» журналы,10.08.2005, № 30, 0695 мәддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кул куелган 880 нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары җыентыгы, 2010, 8 декабрь, № 46, 2144 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә) (алга таба – ТР МК 880 нче номерлы карары).

1.5. Әлеге Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәте – Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар вәкаләтләре чикләрендә торган гариза бирүчеләр соравы буенча тормышка ашырыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органының, шулай ук җирле үзидарә органының функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеге;

административ регламент – дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тәртибен һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү стандартын билгели торган норматив хокукый акт;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) – дәүләт яисә муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында оештырылган (шул исәптән автоном учреждение булып тора торган), 210-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча оештырылган оешма»;

«бер тәрәзә» принцибы – гариза бирүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле соравы яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.маддәсендә күрсәтелгән сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүе, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар белән үзара хезмәттәшлек итү, КФҮ норматив хокукый актлары һәм үзара хезмәттәшлек турындагы килешү нигезендә мөрәҗәгать итүченең катнашыннан башка гамәлгә ашырыла;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 нчы номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәсенең 34 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль үзенә аерым структур бүлекчәсе (офисы);

гариза – 210-ФЗ номерлы Федераль законның маддәсе 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорау (запрос) (тәкъдим ителә торган форма 1 нче кушымтада китерелгән);

аттестация – педагогик хезмәткәрләрнең квалификация дәрәҗәсенең квалификация категорияләренә (беренче яки югары) куела торган таләпләргә туры килү-килмәвен билгеләү;

аттестация уздыручы орган – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы;

аттестация комиссиясе – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы белән педагогик хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен төзелә торган комиссия;

аттестация комиссиясе карары – аттестация уза торган гариза бирүченең гариза бирелгән квалификация категориясенә (беренче яки югары) куела торган таләпләргә туры килүе (килмәве) турында комиссия нәтиҗәләре;

квалификация категориясе – аттестацияләнүче педагогик хезмәткәрнең квалификация дәрәҗәсенең норматив таләпләргә туры килүен бәяләүне чагылдыра торган күрсәткеч;

аттестация процедурасы – аттестация процессын гамәлгә ашыру өчен эзлекле гамәлләрнең билгеләнгән тәртиптә расланган һәм рәсми рәвештә үтәүгә күрсәтелгән стандарт җыелмасы;

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) шулар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яисә аның законлы вәкиленең министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан әлеге мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алганда хокукларын яки законлы

мәнфәгатьләрен яңадан торгызу яисә яклау турында таләбе.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1 Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү | 273-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы; Аттестация тәртибе;<br>315 номерлы Нигезләмә |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Спорт Министрлыгы (алга таба – Министрлык) | 273-ФЗ номерлы Федераль закон 49 маддә 3 нчепункт;<br>68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>315 номерлы Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | Министрлыкның беренче яки югары квалификация категориясен билгеләү турында боерыгы;<br>Аттестация комиссиясенең беренче (югары) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында карары (беренче яки югары квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында беркетмәдән өземтә) | Аттестация тәртибенең 39, 44 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт | Аттестация үткәрү турында педагогик хезмәткәрләрнең гаризалары аттестация комиссиясе | Аттестация тәртибенең 32, 33 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып; әгәр Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | тарафыннан аларны алганнан соң 30 көннән дә артык булмаган вакыт эчендә карала,бу вакыт эчендә:<br>а) элек билгеләнгән квалификация категориясенең гамәлдә булу вакытын исәпкә алып, һәр педагогик хезмәткәр өчен аттестация үткәрүнең индивидуаль конкрет вакыты билгеләнә.;<br>б) педагогик хезмәткәрләргә аларны аттестацияләү вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр итү гамәлгә ашырыла.<br>Һәр гариза бирүче өчен аттестациянең дәвамлылыгы аны үткәрү башланганнан алып һәм аттестация комиссиясе карары кабул ителгәнчегә кадәр 60 календарь көннән дә артмый.<br>Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада да, аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | • Педагогик хезмәткәрләргә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документ булып квалификация категориясен билгеләү максатларында аттестация үткәрү турында гариза бирүченең гаризасы тора (1 нче кушымта).<br><br>Гаризада гариза бирүченең һөнәри дәрәҗәсе һәм белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре турында гариза бирелгән квалификация категориясе таләпләренә туры килә торган белешмәләр булырга тиеш.<br>Гариза аттестация комиссиясенә бирелә.<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Министрлык сайтында урнаштырылган. | Аттестация тәртибенең 27, 28, 30, 36, 37 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | Гаризаны гариза бирүче кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән бирергә (җибәрергә) мөмкин: шәхсән (ышанычнамәсе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан); тапшыру турында билге белән заказлы хат белән почта аша. Гариза шулай ук гомуми кулланылыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган һәм Гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларының тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документлар таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| яисә оешма | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү таләп ителә һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органы тормышка ашыра торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структура бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү каралмый. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Гаризада мәҗбүри мәгълүматларның булмавы | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигез юк.<br>Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>1. Педагогик хезмәткәр тарафыннан, аттестация беренче тапкыр үткәрелә торган вазыйфасы буенча югары квалификация категориясен билгеләү максатында, әлеге вазыйфа буенча беренче квалификация категориясе билгеләнгәннән соң ике елдан иртәрәк аттестация үткәрү турында гариза тапшыру.<br>2. Бирелгән белешмәләрнең беренче яки югары квалификация категориясен бирү таләпләренә туры килмәве. | Аттестация тәртибенең 30, 36, 37, 38 пунктлары |
| 2.10. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте бушлай нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәп | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түр түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Министрлыкка гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы сорау (запрос) биргәндә һәм Министрлыкта мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | РФ Президенты 601Указының 1 нче пункты |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, соравын (запрос) теркәү вакыты | Гариза кергәннән соң бер эш көне эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорау (запрос) ял (бәйрәм) эш көненнән соң икенче көнне теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда | ТР МК 880 нче номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә, шундый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиале мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата таләпләр | һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз үтеп керү мөмкинлеге (бинага керү-чыгу һәм аларның чикләрендә күчерү) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәптә тотып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытта вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте алуның дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең КФҮдә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләрне дә файдаланып, мәгълүмат алу | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы<br>2. Белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы<br>3. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында, шул исәптән электрон формада да, тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеге<br>4. «Интернет» челтәрендә Министрлыкның мәгълүмати ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге.<br>5. Документларны кабул итү алып барыла торган | |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкинлеге | биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы.<br><br>6. Башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулый торган, инвалидлар өчен биналарның файдалана алырлык булуын тәэмин итү белән бәйле булмаган киртәләрне узуда инвалидларга ярдәм күрсәтү.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>1. гаризаларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2. дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу вакытын үтәү;<br>3. дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан кылынган Административ регламентны бозуга нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.<br>Гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара тәэсир итешүе Министрлыкка сорау (запрос) биргәндә гамәлгә аша. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүче белән вазыйфаи затның үзара тәэсир итешүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Гариза бирүче электрон рәвештә сорау (запрос) белән мөрәҗәгать иткән очракта гариза бирүченең Министрлыкның вазыйфаи заты белән үзара тәэсир итешүе бер тапкыр – гариза бирүченең турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза гариза бирүче тарафыннан гомуми кулланылыштагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләр, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |

### 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтә урнашкан эш урыннарында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ процедураларын башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта административ процедураларны эзлеклелеген сурәтләү.

3.1.1. Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган, консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны карау һәм аның буенча карар кабул итү;

4) квалификация категориясен (беренче яки югары) билгеләү максатларында гариза бирүчегә аттестация үткәрү);

5) гариза бирүчене аттестацияләү нәтиҗәләре турында аттестация комиссиясе карарын раслау;

6) техник хатаны төзәтү;

7) КФҮ (КФҮнең ерактагы эш урыны) аша дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, Гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә.

Гариза бирүче бүлеккә дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе турында консультация алу өчен шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон почта) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гариза кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче Министрлыкка турыдан-туры аттестация комиссиясенә квалификация категориясен билгеләү максатларында аттестация үткәрү

турында гариза тапшыра, яисә аттестация комиссиясе адресына почта аша тапшыру турында хәбәр белән хат яки, электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә хәбәр белән хат җибәрә.

3.3.2. Бүлек белгече гариза бирүче тарафыннан бирелгән гаризаны кабул итә, анда мәҗбүри мәгълүматлар булуын тикшерә.

Гаризада әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән мәҗбүри мәгълүмат булмаган очракта Бүлек белгече гариза кабул итүдән баш тарта.

Гариза кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны теркәү;

гариза кабул итү датасы турында тамга белән гариза күчермәләрен тапшыру (гаризаны шәхси тапшырганда).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

1) Гаризаны кабул итүдән баш тарткан очракта гариза бирүчегә гариза кире кайтарыла.

2) Баш тарту өчен нигез булмаган очракта – теркәлгән гариза.

3.4. Гаризаны карау һәм аның буенча карар кабул итү.

3.4.1. Бүлек белгече аттестация комиссиясен карау өчен гариза бирүчеләр исемлеген формалаштыра.

Гариза бирүче аттестация процедуралары башланганчы үз гаризасын язмача кире алырга хокуклы.

Педагогик хезмәткәрләрнең аттестация үткәрү турында гаризаларын аттестация комиссиясе алар алынган көннән алып 30 календарь көннән дә артык булмаган вакыт эчендә карый.

3.4.2. Гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча Аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) Гариза бирүчегә беренче яисә югары квалификация категориясен билгеләү максатларында аңа аттестация уздыру турында, (элек билгеләнгән квалификация категориясенең гамәлдә булу срогын исәпкә алып, һәр гариза бирүче өчен индивидуаль рәвештә аттестация үткәрүнең конкрет вакыты билгеләнә). Аларны аттестацияләү вакыты һәм урыны турында педагогик хезмәткәрләргә язмача хәбәр ителә.

2) Гариза бирүчегә беренче яисә югары квалификация категориясен билгеләү максатларында аны аттестацияләүдән баш тарту турында.

3.4.3. Әлеге Административ регламентның 2.9 пунктында аңа беренче яки югары квалификация категориясен билгеләү максатларында гариза бирүчене аттестацияләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр күрсәтелгән.

3.4.4. Аттестация үткәрү өчен Бүлек белгече:

Квалификация категориясен билгеләү максатларында аттестация үткәрүгә гариза биргән педагогик хезмәткәрләрнең мәгълүматлар базасына гариза

бирүче турында мәгълүмат кертә;

гариза бирүчене педагогик хезмәткәрләргә аттестация үткәрү графигына кертә;

квалификация категориясен билгеләү максатларында педагогик хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында боерык проектына гариза бирүче турында мәгълүмат кертә;

боерык проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.4.2 подпункта каралган процедура тәмамланганнан соң, гариза кергән очракта ай саен 3 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Килешенгән боерык проекты раслауга министрга җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: раслауга юнәлдерелгән боерык.

3.4.5. Министр аттестация үткәрү турында боерык раслый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 3.4.4 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган боерык.

3.4.6. Бүлек белгече гариза бирүчеләргә язмача хәбәр итә:

1) Гариза бирүчегә беренче яки югары квалификация категориясен билгеләү максатларында аңа аттестация үткәрү турында карар кабул ителгән очракта – аларны аттестацияләүне уздыру вакыты һәм урыны күрсәтелеп, аттестация уздыру турында расланган боерык.

2) Гариза бирүчегә беренче яки югары квалификация категориясен билгеләү максатларында аңа аттестация үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта – мондый карар кабул итү нигезләре турында.

Процедураларның нәтиҗәсе:

1) гариза бирүчегә беренче яисә югары квалификация категориясен билгеләү максатларында аңа аттестация үткәрү турында юлланган боерык.

2) Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында юлланган хат.

3.5. Квалификация категориясе (беренче яки югары) билгеләү өчен гариза бирүчене аттестацияләү үткәрү.

3.5.1. Һәр гариза бирүче өчен аттестация дәвамлылыгы аны үткәрү башланганнан алып аттестация комиссиясе тарафыннан карар кабул иткәнчегә кадәр 60 календарь көннән дә артмый.

Беренче квалификация категориясе түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 августыннан «Мәгариф системасы мониторингын гамәлгә ашыру турында» 662 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган мәгариф системасын мониторинглау йомгаклары буенча укучыларның белем бирү программаларын үзләштерүнең тотрыклы уңай нәтиҗәләре.

2) Укучыларның фәнни (интеллектуаль) иҗади, физкультура-спорт

эшчәнлегенә сәләтләренең үсешен ачыклау.

3) Белем бирү сыйфатын күтәрүгә, укыту һәм тәрбия ысулларын камилләштерү, педагогик коллективларда үз һөнәри эшчәнлегенең гамәли нәтиҗәләре тәҗрибәсен трансляцияләү, оешма педагогик хезмәткәрләренең методик берләшмәләре эшендә актив катнашу.

Югары квалификация категориясе түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 августыннан «Мәгариф системасы мониторингын гамәлгә ашыру турында» 662 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә оешмалар тарафыннан үткәрелә торган мәгариф системасын мониторинглау йомгаклары буенча укучыларның белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренең уңай динамикасына укучыларның ирешкән казанышлары.

2) Укучыларның фәнни (интеллектуаль), иҗади, физкультура-спорт эшчәнлегенә сәләтләрен ачыклау һәм үстерү, шулай ук аларның олимпиадаларда, конкурсларда, фестивальләрдә, ярышларда катнашуы.

3) Белем бирү сыйфатын күтәрүгә, укыту һәм тәрбия ысулларын камилләштерү, яңа белем бирү технологияләреннән нәтиҗәле файдалану, педагогик коллективларда үз һөнәри, шул исәптән эксперименталь һәм инновацион эшчәнлегенең практик нәтиҗәләре тәҗрибәсен трансляцияләү.

4) Белем бирү процессын программалы-методик тәэмин итү буенча оешма педагогик хезмәткәрләренең методик берләшмәләре эшендә, һөнәри бәйгеләрдә актив катнашу.

3.5.2. Бәйсез аттестация экспертлары эшчәнлеген оештыру өчен Бүлек белгече:

мөрәҗәгать итүчене, бәйсез аттестация экспертларын җәлеп итеп, һөнәри экспертиза узуга тиешле педагогик хезмәткәрләр составы исемлегенә кертә;

гариза бирүченең белем бирү эшчәнлеге (спорт төре) юнәлешен исәпкә алып, бәйсез аттестация экспертлары составын төзи;

бәйсез аттестация экспертларының гариза бирүчеләргә чыгуның башлангыч графигын әзерли;

гариза бирүченең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза оештыру турында боерык проектын әзерли;

боерык проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.4.5 подпунктында каралган процедураны тәмамлаганнан соң биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Килешенгән боерык проекты раслауга министрга җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: раслауга юнәлдерелгән боерык.

3.5.3. Министр гариза бирүченең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза оештыру турындагы боерыкны раслый һәм Министрлык Бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 3.5.2 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган боерык.

3.5.4. Бүлек белгече боерыкны экспертларга – командировка өчен нигез

буларак, министрлык карамагындагы оешмалар җитәкчесенә, физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органнарына – гариза бирүчегә һәм аның эш бирүчесенә экспертиза үткәрү графигы турында хәбәр итү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 3.5.3 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң ике календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: экспертларга, министрлыкка караган оешмалар җитәкчеләренә, муниципаль берәмлектәге физик культура һәм спорт өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органнарына юлланган гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза оештыру турында боерык.

3.5.5. Бәйсез аттестация эксперты гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза оештыру турындагы боерыкта билгеләнгән вакыт эчендә гариза бирүченең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренең дәүләт норматив таләпләренә (шул исәптән электрон рәвештә дә) туры килү-килмәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Эксперт нәтиҗәләре нигезләү белән бүлек белгеченә җибәрелә торган эксперт бәяләмәсенә кертелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, бәйсез экспертларның эш графигы нигезендә, гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә экспертиза оештыру турындагы боерык буенча Министрлыкның аттестация комиссиясендә карар кабул итүгә кадәр егерме биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: эксперт бәяләмәләре.

3.5.6. Бүлек белгече аттестация комиссиясе утырышының көн тәртибен әзерли, аттестация комиссиясе утырышында тыңлау һәм аларның билгеләнгән квалификация категориясенә туры килүе (туры килмәве) турында Карар кабул итү өчен тапшырылган эксперт нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәләре буенча документлар пакетын формалаштыра һәм аттестация комиссиясе сәркатибенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар хезмәткәрнең һөнәри нәтиҗәләренә тышкы экспертиза үткәрү датасы һәм аттестация комиссиясе утырышын үткәрү датасы арасында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: аттестация комиссиясе утырышының көн тәртибе, аттестация комиссиясе секретаренә тапшырылган документлар пакеты.

3.5.7. Аттестация комиссиясе секретаре утырыш үткәрү урынын һәм вакытын тәгаенләштерү буенча эш алып бара, аттестация комиссиясе әгъзаларына, экспертларга хәбәр итә, утырышта катнашырга теләк белдергән гариза бирүчегә утырыш уздыру датасы һәм урыны турында хәбәр итә.

3.5.8. Эксперт төркеменең эксперт бәяләмәләре нигезендә аттестация комиссиясе педагогик хезмәткәрләрнең квалификация категориясенә туры килүе (туры килмәве) турында соңгы карарны кабул итә.

Аттестация комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәгә тавыш бирүдә катнашкан аттестация комиссиясе әгъзалары имза сала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар комиссия утырышы узган көнне гамәлгә ашырыла.

3.5.9. Комиссия утырышлары Министрлык тарафыннан расланган аттестация комиссиясе утырышлары графигы нигезендә, әмма гариза бирүчеләрнең һөнәри нәтиҗәләренә экспертиза оештыру турындагы боерык нигезендә үткәрелә торган экспертиза процедурасы башланганнан соң ике айдан да соңга калмыйча уздырыла. Утырыш нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе секретаре Бүлек белгеченә аттестация комиссиясенең уңай карарга аерым, тискәре карарга аерым имзаланган беркетмәсен тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: аттестация комиссиясе беркетмәсе.

3.6. Гариза бирүчене аттестацияләү нәтиҗәләре турында аттестация комиссиясе карарын раслау.

3.6.1. Бүлек белгече гариза бирүчегә карата аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән гариза бирүчегә бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләү турында боерык проектын әзерли, гариза бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында аттестация комиссиясе беркетмәсеннән өземтә әзерли һәм килештерүгә министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 3.5.9 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: педагогик хезмәткәргә гариза бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләү турында боерык проекты, гариза бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында аттестация комиссиясе беркетмәсеннән өземтә.

3.6.2. Министрның беренче урынбасары боерык проектын килештерә һәм министрга раслауга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура 3.6.1 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга раслауга юлланган боерык проекты, гариза бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында аттестация комиссиясе беркетмәсеннән өземтә.

3.6.3. Министр педагогик хезмәткәргә гариза бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләү турында боерыкны раслый һәм Белгечкә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура 3.6.2 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган боерык, гариза бирелгән (беренче яки югары) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында аттестация комиссиясе беркетмәсеннән өземтә.

3.6.4. Бүлек белгече түбәндәгеләрне тормышка ашыра:

гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турында боерыкны физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органнарына, гариза бирүчегә хезмәт өчен түләүнең тиешле дәрәҗәсен билгеләү өчен оешмаларга җибәрү;

гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында аттестация комиссиясе беркетмәсеннән өземтә җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.6.3 подпунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: юлланган боерык, гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясен билгеләүдән баш тарту турында аттестация комиссиясе беркетмәсеннән өземтә.

3.7. Техник хатаны төзәтү.

Югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турындагы боерыкны яңадан рәсмиләштерү югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турындагы боерыкта җибәрелгән техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата) юкка чыгаруга бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла (алга таба – Боерык).

Боерыкны яңадан рәсмиләштерү, техник хаталы боерыкны теркәп бирелгән гариза (тәкъдим ителгән форма  3нче кушымтада китерелгән) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне тормышка ашыра:

техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү;

электрон документ әйләнешенең ведомствоара системасы аша техник хаталарны төзәтү турында министрга гариза җибәрү.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган Процедура техник хаталарны бетерү турындагы гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза.

3.7.2. Министр техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура техник хаталарны бетерү турындагы гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерүгә министрның беренче урынбасарына җибәрелгән техник хаталарны төзәтү турында гариза.

3.7.3. Министрның беренче урынбасары техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура техник хаталарны бетерү турындагы гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карауга җибәрелгән техник хаталарны төзәтү турында гариза.

3.7.4. Бүлек җитәкчесе Бүлек белгечен билгели һәм аңа башкару өчен техник хаталарны төзәтү турында гаризаны тапшыра.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура техник хаталарны бетерү турындагы гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә юлланган техник хаталарны төзәтү турында гариза.

3.7.5. Бүлек Белгече:

яңа редакциядә боерык проектын һәм гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

3.7.6. Бүлек башлыгы яңа редакциядә әзерләнгән Боерык проектының дөреслеген тикшерә, гариза бирүчегә хат проектын килештерә һәм аларны килештерүгә министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгына килештерүгә яңа редакциядә боерык проекты һәм хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерүгә министрның беренче урынбасарына юлланган боерык проекты һәм хат проекты.

3.7.7. Министрның беренче урынбасары гариза бирүчегә теркәп бирелә торган яңа редакциядәге боерык белән хат проектын килештерә һәм бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: яңа редакциядәге боерык проекты теркәлгән килештерелгән хат проекты.

3.7.8. Бүлек белгече килештерелгән хат проектын һәм яңа редакциядәге боерыкны министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура хат һәм яңа редакциядәге боерык проекты министрның беренче урынбасары килештергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга кул куюга юлланган хат проекты һәм яңа редакциядәге боерык проекты.

3.7.9. Министр гариза бирүчегә хат проектын һәм яңа редакциядәге боерык проектын имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган роцедура министрга кул куюга җибәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр имзалаган хат һәм яңа редакциядәге боерык.

3.7.10. Бүлек белгече түбәндәгене тормышка ашыра:

физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарына хезмәт өчен түләүнең тиешле дәрәҗәсен билгеләү өчен гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турында хат һәм яңа редакциядәге боерык җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.9 подпунктында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә югары (беренче) квалификация категориясен билгеләү турында җибәрелгән хат һәм боерык.

3.8. Күпфункцияле үзәк, КФҮнең ерак урнашкан эш урыны аша дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе.

Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәктә, КФҮнең читтән торып эш урыны аша күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедураларны үтәүне тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмә бирелә.

4.1. Җаваплы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган Административ регламент һәм башка норматив хокукый актлар нигезләмәләрен саклауны һәм аларның үтәлешен, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшереп тору Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләрне карау, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне тикшерү формалары булып түбәндәге тикшерүләрне үткәрү тора:

эш башкаруны алып баруны;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклауны;

дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәүне.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.2. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозган очракларны ачыклаган чакта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы гаепле дип танылган затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирү

5.1. Гариза бирүчеләрнең Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар.

Министр тарафыннан кабул ителгән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда да:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакытын бозган очракта;

- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозганда;

- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тәкъдим ителергә тиеш булмаган документлар яки мәгълүматларны яки тормышка ашырылу каралмаган гамәлләрне таләп иткәндә;

- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тартканда;

- әгәр баш тарту өчен нигезләмәләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

- әгәр туктату өчен сәбәпләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;

- Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартканда яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозган чагында;

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 маддәсенең 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире кагу вакытында аларның булмавы яисә дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minsport.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы

(http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – теркәлгән көннән алып 15 эш көне дәвамында.

Дәүләт хезмәте күрсәтә торган министрлыкка яисә дәүләт хезмәте күрсәтә торган министрлыкның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән язудагы һәм басмадагы хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять белдергән очракта яисә мондый төр төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять язган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында тормышка ашырылырга тиеш.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең атамасы;

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) белән килешмәгән дәлилләр. Гариза бирүче үз фикерләрен дәлилле торган документлар (булган очракта) яки аларның күчерелмәләрен бирергә хокуклы.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәсе буларак түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда язуда һәм басмада җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчалата чараларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә шикаять канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6. Гариза бирүчегә, карарны кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап юллана.

Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип таныган очракта, гариза бирүчегә адресланган җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен гафу үтенелә һәм алга таба дәүләт хезмәтен алу максатында гариза бирүчегә башкарырга кирәк булган эш-гамәлләр турында мәгълүмат

бирелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп нигезле аңлатма, шулай ук әлеге карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау дәвамында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган барлык материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасында квалификация
категориясен билгеләү максатларында
физик культура һәм спорт өлкәсендә белем
бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем
бирү программаларын тормышка ашыра
торган оешмаларның педагогик
хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан
Республикасы Спорт министрлыгының
Административ регламентына
1 нче кушымта
(тәкъдим ителгән форма)

___________________________________________
(аттестация комиссиясе атамасы)

___________________________________________

___________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме)

___________________________________________
(вазыйфа, эш урыны)

ГАРИЗА

Мине 20__ елда ____________________________________________________ вазыйфасы (вазыйфалары) буенча ______________________________________ квалификация категориясе буенча аттестацияләвегезне сорыйм.

Бүгенге көндә (_____________________________вазыйфасы буенча ____________________квалификация категориясенә иямен, ул ________________________________
гамәлдә булу вакыты бетә торган көн, ай һәм елны күрсәтергә

кадәр гамәлдә) яисә (квалификаця категориясенә ия түгелмен).

Гаризада күрсәтелгән квалификация категориясе буенча аттестация узу өчен _________________ квалификация категориясенә[1] куела торган таләпләргә туры килә торган түбәндәге эш нәтиҗәләрен нигез дип саныйм: _____________________________________________.

Үзем турында түбәндәге мәгълүматны җиткерәм:

Белем дәрәҗәсе (белем алган оешманы кайда һәм кайчан тәмамлау, алынган белгечлек һәм
квалификация)______________________________________________________________________
________________________________________________________________________________________
_______.

педагогик эш стажы (белгечлек буенча) ______ел, әлеге вазыйфада __________________ ел; әлеге оешмада ____________________ ел.

Түбәндәге бүләкләргә, исемгә, фәнни дәрәҗәгә, фәнни исемгә иямен ________________________________________________________________________________________
__.

Квалилфикация күтәрү турында мәгълүмат (курс буенча укыту кайда һәм кайчан үткәрелгән, сәгатьләр саны, тематикасы,раслый торган

[1] Эш нәтиҗәләре турында мәгълүмат гаризага кушымта буларак тәкъдим ителә ала.

документ)____________________________
_____________________________________________________________________________________.

Аттестацияләүне аттестацияләү комиссия утырышында минем катнашта (минем катнашымнан башка) (кирәгенең астына сызарга) үткәрүегезне сорыйм.

Белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе белән танышмын, шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризамын.


«____» _____________________ 20___ ел Имза _______________________

Шәхси телефон _____________________, Эш телефоны____________

Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Административ регламентына
2 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




Министр
Боерыкларга кул куя
Белгеч
Аттестацияләү, экспертиза үткәрү турындагы боерыкларны юллый
Экспертлар
3.5.5 п. белән каралган гамәлләрне башкара
Эксперт бәяләмәсе
Белгеч
3.5.8 п. белән каралган гамәлләрне башкара
Аттестацияләү комиссииясе утырышның көн тәртибе, аттестацияләү комиссиясе сәркатибенә юлланган документлар пакеты
Аттестацияләү комиссиясе сәркатибе
Комиссия утырышын оештыру буенча эш башкара
Комиссия әгъзаларына утырыш көне турында хәбр итү
Аттестацияләү комиссиясе
Дәгъва ителгән категориягә туры килү (килмәү) турында соңгы карар кабул итә
Аттестацияләү комиссиясе беркетмәсе
әйе
юк
Категория бирү турында карар кабул ителә
Белгеч
Дәгъва ителгән квалификация категориясен бирү турында боерык проектын әзерли
Белгеч
Дәгъва ителгән квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында беркетмәдән өземтә әзерли
Министрның беренче урынбасары
Боерыкны килештерә
Министрның беренче урынбасары
Өземтәне килештерә
Министр
Боерыкка кул куя
Министр
Беркетмәдән өземтәгә кул куя
Белгеч
Квалификация категориясен бирү турында боерыкны юллый
Белгеч
Дәгъва ителгән квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында өземтәне юллый
Юлланган боерык
Гариза бирүчегә юлланган өземтә

Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Административ регламентына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы спорт министрына

___________________________________
(җитәкченең ФИАи.)

_______________________________________________
(оешма атамасы, оешма җитәкчесенең яисә оешма вәкиленең ФИА.и.)

_______________________________________________

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

Документлар тапшырган чакта җибәрелгән хата (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) турында хәбәр итәм.

_______________________________________________________________________
(тапшырылган документ)
_____________________________ дип күрсәтелгән:
_______________________________________________________________________
Дөрес мәгълүмат: _________________________________________________
_______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Әзерлек хакында миңа
_______________________________________________________________________
(хәбәр итү ысулы)
аша миңа хәбәр итүегезне сорыйм.

_______________ _______________ (______________________)
(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасында квалификация
категориясен билгеләү максатларында
физик культура һәм спорт өлкәсендә белем
бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем
бирү программаларын тормышка ашыра
торган оешмаларның педагогик
хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Татарстан
Республикасы Спорт министрлыгының
Административ регламентына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасында квалификация категориясен билгеләү максатларында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм белем бирү программаларын тормышка ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222-81-01<br>Факс:<br>(843) 222-81-79 | minsport@tatar.ru<br>http://minsport.tatarstan.ru/ |
| Министрның беренче урынбасары | (843) 222-81-03<br>Факс:<br>(843) 222-81-79 | minsport@tatar.ru |
| Бүлек мөдире | (843) 222-81-18 | Y.Semenova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы | +7 (843) 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |